**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**№ 1** **15 ноябрь 2023 ел**

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юртау авыл җирлеге Юртау торак пунктында 2024 елда гражданнардан үзара салым кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юртау авыл җирлегенең Юртау торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юртау авыл җирлегенең Юртау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан һәм һәм Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнар, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәгеләргә җибәрергә:

- тукталыш павильонын сатып алу һәм урнаштыру (тукталыш пункты);

- Юртау бистәсендә җәйге вакытта территориядә үлән чаптыру(ягулык-майлау материаллары, триммер өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү).

3. Әлеге карарны Юртау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ menzelinsk.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Юртау авыл җирлеге башлыгы И.Ю.Кадыров